РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Советская, д. 41в , село Татарский Шуган, Азнакаевского муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» октябрь 2023 ел №3

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татар Шуганы авылы Ленин ур., 1 нче йорттан 31 нче йортка кадәр, Совет урамы 43, 45, 47, 49 нчы йортлар,51нче йорттан 90 нчы йортка кадәр,Җәлил урамы, 1 нче йорттан 10нчы йортка кадәр, Х. Такташ урамы, 1 нче йорттан 22нче йортка кадәр , Сәйдәшев урамы 1 нче йорттан 25нчы йортка кадәр , Сөембикә урамы 1 нче йорттан 3нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы,Азнакай районы,Татар Шуганы авылы,Совет урамы 41б йорт адресы буенча урнашкан мэдэният йортында2023 елның 19 октябрендэ 13.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татар Шуганы авылы Совет ур., 1 нче йорттан 42,44,46,48,50нче йортка кадәр , Тукай ур., 1 нче йорттан 45 нче йортка кадәр, Молодежная ур., 1 нче йорттан 12 нче йортка кадәр, Новая ур., 1 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы,Азнакай районы,Татар Шуганы

авылы,Совет урамы 41б йорт адресы буенча урнашкан мэдэният йортында2023 елның 19 октябрендэ 15.00 сәгатькә билгеләргә.

3. «Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар очен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү, "Урта" чишмәне төзекләндерү;

2) торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистартканда трактор йөртүче хезмәтләренә түләү);

3) халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзү, ремонтлау – Татар Шуганы авылынын Сабантуйны уздыру урынын тозеклэндеру һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.Ш.Хэертдинов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР-ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ТАТАРСКО-ШУГАНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ